Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Шәһәр тибындагы
Совет поселогы
423060, Аксубай штп,
Советлар урамы, 2 нче йорт
т.2-73-62

Совет поселка городского типа
Аксубаево
Аксубаевского муниципального района
Республики Татарстан
423060, пгт Аксубаево,
ул.Советская, д.2
т. 2-73-62

# КАРАР

17.04. 2021 ел №25

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Советының «Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2021 елның 5 мартындагы 19 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы шәһәр тибындагы Аксубай шәһәр тибындагы поселогы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы шәһәр тибындагы Аксубай бистәсе Советының «Җирле салымнар буенча түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2021 елның 5 мартындагы 19 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның преамбуласында «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Түләттерүгә өметсез дип танылган түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны бетерү Тәртибен һәм түләнеп бетмәгән салымны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар Исемлеген раслау турында» 19.08.2010 ел, № ЯК-7-8/393@ боерыгы» сүзләрен «Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең «Түләттерүгә өметсез дип танылган түләнеп бетмәгән салымны һәм пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны бетерү Тәртибен һәм түләнеп бетмәгән салымны, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тану шартларын раслаучы документлар Исемлеген раслау турында» 02.04. 2019ел, № ММВ-7-8/164@ боерыгы» сүзләренә

алмаштырырга.

1.2. 2 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында(http://aksubayevo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:/ / pravo. tatarstan. ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Аксубай штп Советының финанс һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Аксубай штп башлыгы,
Аксубай штп Советы рәисе: К.К. Гилманов